# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

**«15» ноябрь 2021 ел № 35 Югары Кибәхуҗа авылы**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 24.11.2014 №82 "Физик затлар милкенә салым турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

2018 елның 3 августындагы 334-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 24.11.2014 №82 "Физик затлар милкенә салым турында" карарына (14.05.2015 ел N 107, 12.10.2015 ел №3, 30.11.2018 №91 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле «, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан» сүзләрен өстәргә;»;

2) 3 пунктта:

А) 1 пунктның өченче абзацында «дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

Б) 2 пунктчасын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

« 2) 0,2% түбәндәгеләргә карата:

торак йортларның, торак йортларның өлешләренең, фатирларның, фатирларның өлешләренең, бүлмәләрнең өлешләренең»;

В) 3 пунктчада икенче абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
4. 1 пунктның 1 пунктчасының өченче абзацы нигезләмәләренең гамәлдә булуы физик затлар мөлкәтенә салымны 2017 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Югары Кибәхуҗа
авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Мәхмүтов